ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешү раслау хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 6 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм кайбер актлары аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану турында» 2023 елның 20 апрелендәге 623 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары кабул ителүгә бәйле рәвештә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен бюджет кредиты бирү турында 2009 елның 18 декабрендәге 01-01-06/06-441 номерлы, 2010 елның 27 февралендәге 01-01-06/06-56 номерлы, 2010 елның 19 апрелендәге 01-01-06/06-112 номерлы, 2010 елның 5 августындагы 01-01-06/06-280 номерлы, 2010 елның 22 декабрендәге 01-01-06/06-595 номерлы, 2011 елның 27 апрелендәге 01-01-06/06-66 номерлы, 2012 елның 12 апрелендәге 01-01-06/06-60 номерлы, 2012 елның 8 июнендәге 01-01-06/06-94 номерлы, 2012 елның 12 июлендәге 01-01-06/06-125 номерлы, 2012 елның 4 октябрендәге 01-01-06/06-307 номерлы килешүләргә һәм федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш) төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту өчен бюджет кредиты бирү турында 2010 елның 18 мартындагы 01-01-06/06-71 номерлы, 2010 елның 18 октябрендәге 01-01-06/06-394 номерлы, 2011 елның 22 мартындагы 01-01-06/06-28 номерлы, 2011 елның 1 августындагы 01-01-06/06-187 номерлы килешүләргә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелгән 2024 елның 11 апрелендәге 7/7/7/7/7/7/6/5/5/5/6/7/7/7 номерлы өстәмә килешүне әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 14 июнь
№ 43-ТРЗ

«Федераль бюджеттан
Татарстан Республикасы бюджетына
бюджет кредитлары бирү турындагы
килешүләргә өстәмә килешү
раслау хакында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен бюджет кредиты бирү турында 2009 елның 18 декабрендәге 01-01-06/06-441 номерлы, 2010 елның 27 февралендәге 01-01-06/06-56 номерлы, 2010 елның 19 апрелендәге 01-01-06/06-112 номерлы, 2010 елның 5 августындагы 01-01-06/06-280 номерлы, 2010 елның 22 декабрендәге 01-01-06/06-595 номерлы, 2011 елның 27 апрелендәге 01-01-06/06-66 номерлы, 2012 елның 12 апрелендәге 01-01-06/06-60 номерлы, 2012 елның 8 июнендәге 01-01-06/06-94 номерлы, 2012 елның 12 июлендәге 01-01-06/06-125 номерлы, 2012 елның 4 октябрендәге 01-01-06/06-307 номерлы килешүләргә һәм федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш) төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту өчен бюджет кредиты бирү турында 2010 елның 18 мартындагы 01-01-06/06-71 номерлы, 2010 елның 18 октябрендәге 01-01-06/06-394 номерлы, 2011 елның 22 мартындагы 01-01-06/06-28 номерлы, 2011 елның 1 августындагы 01-01-06/06-187 номерлы килешүләргә
7/7/7/7/7/7/6/5/5/5/6/7/7/7 номерлы

# ӨСТӘМӘ КИЛЕШҮ

Мәскәү шәһәре 2024 елның 11 апреле

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы исеменнән, алга таба «Кредитор» дип аталачак, 2014 елның 15 сентябрендәге 288 номерлы Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы (2018 елның 5 июнендәге 712 номерлы Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы редакциясендә) нигезендә эш итүче Россия Федерациясе Финанс министрының беренче урынбасары Л.В. Горнин, бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән, алга таба «Заемщик» дип аталачак, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм 2017 елның 6 маендагы 273 номерлы Татарстан Республикасы Президенты боерыгы нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошин, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, «Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдындагы йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрүнең өстәмә шартлары һәм тәртибе турында» 2012 елның 18 декабрендәге 1325 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге өстәмә килешүне төзеделәр.

1. Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен бюджет кредиты бирү турында 2009 елның 18 декабрендәге 01-01-06/06-441 номерлы, 2010 елның 27 февралендәге 01-01-06/06-56 номерлы, 2010 елның 19 апрелендәге 01-01-06/06-112 номерлы, 2010 елның 5 августындагы 01-01-06/06-280 номерлы, 2010 елның 22 декабрендәге 01-01-06/06-595 номерлы, 2011 елның 27 апрелендәге 01-01-06/06-66 номерлы, 2012 елның 12 апрелендәге 01-01-06/06-60 номерлы, 2012 елның 8 июнендәге 01-01-06/06-94 номерлы, 2012 елның 12 июлендәге 01-01-06/06-125 номерлы, 2012 елның 4 октябрендәге 01-01-06/06-307 номерлы килешүләргә һәм федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш) төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту өчен бюджет кредиты бирү турында 2010 елның 18 мартындагы 01-01-06/06-71 номерлы, 2010 елның 18 октябрендәге 01-01-06/06-394 номерлы, 2011 елның 22 мартындагы 01-01-06/06-28 номерлы, 2011 елның 1 августындагы 01-01-06/06-187 номерлы килешүләргә 2020 елның 31 июлендәге 5/5/5/5/5/5/4/3/3/3/4/5/5/5 номерлы өстәмә килешүнең (алга таба тиешенчә – килешүләр, 5/5/5/5/5/5/4/3/3/3/4/5/5/5 номерлы өстәмә килешү) 5 пунктындагы «в» пунктчасының беренче абзацын, 2023 елның 30 ноябрендәге 6/6/6/6/6/6/5/4/4/4/5/6/6/6 номерлы өстәмә килешү белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) бюджет кредитлары буенча бурычны каплау күләмен киметү нәтиҗәсендә азат ителә торган Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчаларын инженерлык эзләнүләрен башкаруга, проектлауга, проектлау документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза ясауга, инфраструктура объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм файдалануга тапшыруга, шулай ук «Яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатларында бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе субъектының Россия Федерациясе алдындагы бурычын каплау күләмен киметү нәтиҗәсендә азат ителә торган Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары инженерлык эзләнүләрен башкаруга, проектлауга, проектлау документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза ясауга, инфраструктура объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм файдалануга тапшыруга, шулай ук капиталь төзелеш объектларын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруга (технологик тоташтыруга) җибәрелергә тиешле яңа инвестиция проектларын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 19 октябрендәге 1704 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарында каралган тәртиптә билгеләнә торган яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатларында капиталь төзелеш объектларын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруга (технологик тоташтыруга) һәм Россия Федерациясе субъектларының федераль проектларның максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган региональ проектларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгым йөкләмәләрен тәэмин итүгә, икътисад тармаклары үсешенә геосәяси һәм икътисадый вәзгыятьнең начараю йогынтысын булдырмауга бәйле чараларны финанс белән тәэмин итүгә һәм коронавирус инфекциясен профилактикалауга һәм

аның таралу зыяннарын бетерүгә бәйле чараларны финанс белән тәэмин итүгә җибәрү.».

2. Килешүләрнең һәм 5/5/5/5/5/5/4/3/3/3/4/5/5/5 номерлы өстәмә килешүнең әлеге өстәмә килешүдә кагылмаган һәм аңа каршы килми торган калган шартлары үзгәрми, һәм Яклар алар буенча үз йөкләмәләрен раслыйлар.

3. Әлеге өстәмә килешү килешүләрнең аерылгысыз өлеше булып тора, Яклар тарафыннан аны имзалаган көннән үз көченә керә һәм Яклар тарафыннан килешүләр буенча йөкләмәләрне тулысынча үтәүгә кадәр гамәлдә була.

4. Әлеге өстәмә килешү редакциясендәге 5/5/5/5/5/5/4/3/3/3/4/5/5/5 номерлы өстәмә килешүнең 5 пунктындагы «в» пунктчасының беренче абзацындагы нигезләмәләр «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм кайбер актлары аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану турында» 2023 елның 20 апрелендәге 623 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары үз көченә кергән көннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге өстәмә килешү, һәр Як өчен берәр нөсхә итеп, бертигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә 3 биттә төзелде.

**Урнашу урыны һәм адресы**

**Кредитор** – Россия Федерациясе Финанс министрлыгы, Ильинка урамы, 9, 1 нче бина, Мәскәү шәһәре, 109097.

**Заемщик** – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Ирек мәйданы, 1, Казан шәһәре, 420060.

**Якларның имзалары**

| | |
|---|---|
| **Кредитордан** | **Заемщиктан** |
| Россия Федерациясе<br>Финанс министрының<br>беренче урынбасары | Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры |
| Л.В. Горнин | А.В. Песошин |
| ____________________<br>М.У. | ____________________<br>М.У. |